ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«_12_» ___11___ 2020г.** **№ 873**

2021 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләр хакының нормативларын раслау турында

Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөрткәндә автомобиль транспортыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларына укучылар йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2010 елның 05 июлендәге 545 санлы карары нигезендә Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елга түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

2021 елга гомуми белем бирү оешмаларына балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хаклары нормативларын;

Гомуми белем бирү оешмаларында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда укучылар йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне.

2. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда укучыларны гомуми белем бирү оешмаларына йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативлары нигезендә финанслауны.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе С.П Самонина

Сучкова А.В.
2-80-12

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланды
"___" ____20ел №____

2021 елга гомуми белем бирү оешмаларына балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда укучылар йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәяләре нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставка нормативы күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сум | автотранспорт чарасының бер километр юл узуына ставка, сум |
| КАВЗ | 149595 | 37,79 |
| ПАЗ | 149072 | 37,72 |
| ГАЗ «Газель» | 129791 | 30,61 |
| УАЗ | 129338 | 29,21 |
| FIAT | 132984 | 27,71 |
| Peugeot Boxer | 138182 | 27,36 |
| Ford Transit | 138440 | 30,79 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 151544 | 35,91 |

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланды
"___" ____20ел №____

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына укучылар йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында
Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына укучылар йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакын исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының хисап чорында факттагы үткән юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакы нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда, Татарстан Республикасында кайбер транспорт чаралары өчен бердәм мониторинг системасы мәгълүматлары буенча транспорт маршрутының расланган паспорты кысаларында ясалган транспорт чарасы турында мәгълүмат алына.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m моделендәге автотранспорт чараларының фактта узган юлы;

$NF_{km_m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларына балалар йөртүне оештыру бәясенең нормасы, бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына укучылар йөртүне оештыру бәясенең ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сум;

$M_m$ - m моделендәге автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар моделе саны.